**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авылы җирлеге Киров исемендэге совхоз поселогында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

03.12.2025ел. № 2

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Киров авылы җирлеге Киров исемендэге совхоз поселогында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Киров авыл җирлеге Киров исемендэге совхоз поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар, көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 1000 (бер мен) сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;(- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау хэм карап тоту)

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;(- су белән тәэмин итү корылмаларын ремонтлау хэм карап тоту)

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( урам юлларын ремонтлау, карап тору)

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә590граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны — граждан кертелде.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 177 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
"тоткарланучылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Киров авылы җирлеге Киров исемендэге совхоз поселогында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Киров авыл җирлеге Киров исемендэге совхоз поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар , көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 1000(бер мен) сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;(урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау хэм карап тоту;)

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;(- су белән тәэмин итү корылмаларын ремонтлау хэм карап тоту )

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

кабул ителгән дип танырга.

3. Киров авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Актаныш муниципаль районы
Киров авыл җирлеге Башлыгы Д.Н.Даутов